# КАРАР

**05 апрель 2024 ел №2**

**"Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Яңа Иябаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 14 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Яңа Иябаш авылында гражданнарның җыены нәтиҗәләре турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 , 56 статьяларына, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Яңа Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлегендә Яңа Иябаш авылы 2024 елның 05 апрелендә «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Яңа Иябаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелгән:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Иябаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә түләү күләме 300 сум тәшкил итә, көндезге формада укучы студентларга, 80 яшьтән узган гражданнарга 100 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы?

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Төхвәтуллин урамы 10 йортыннан 20 йортына кадәр 200 метр урам-юл челтәренең юл өслегендәге чокырларны ремонтлау; Төхфәтуллин урамы 45 йорттан Елга Арты урамы тыкрыгына кадәр 60 метр урам-юл челтәренең юл өслегендәге чокырларны ремонтлау).

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

Халык җыены беркетмәсе(йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 257 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 142 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 138 кеше тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 4 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Иябаш авылында халык җыенын булып узган дип таныйрга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.
2. «Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Иябаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә түләү күләме 300 сум тәшкил итә, көндезге формада укучы студентларга, 80 яшьтән узган гражданнарга 100 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы?

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Төхвәтуллин урамы 10 йортыннан 20 йортына кадәр 200 метр урам-юл челтәренең юл өслегендәге чокырларны ремонтлау; Төхфәтуллин урамы 45 йорттан Елга Арты урамы тыкрыгына кадәр 60 метр урам-юл челтәренең юл өслегендәге чокырларны ремонтлау)

- мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип таныйрга».

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына Татарстан Республикасы , Арча районы, Яңа Иябаш авылы, Төхвәтуллин урамы, 8а йорты адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров